ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

15.03.2019 № 113

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү, тиешле тәртиптә тоту, җыештыруны оештыру, чисталык һәм тәртип тәэмин итү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» , 2017 елның 29 декабрендәге 463 – ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» законы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында " Федераль законы ,2004 елның 28 июлендәге 45 - ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак – коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Җирлекләр, шәһәр округлары, шәһәр эче округлары территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләрен әзерләү өчен методик рекомендацияләрне раслау турында "гы 2017 елның 13 апрелендәге 711/пр номерлы боерыгы , Менделеевск муниципаль районының «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә , Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Камай авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының 2018 елның 20 февралендә кабул ителгән 69 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү, тиешле тәртиптә тоту, чисталык һәм тәртип

кагыйдәләрен раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү, тиешле тәртиптә тоту, чисталык һәм тәртип кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) "Камай авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен карап тоту» исемле 3 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 3.11 пункт өстәргә:

« 3.11. Җир кишәрлекләре " Сосновский балтырганын" бетерү буенча чаралар.

Милкендә яки файдалануда җир кишәрлекләре булган затлар үзләренең җир кишәрлекләрендә "Сосновский балтырганын" бетерү буенча чаралар күрергә тиеш.

"Сосновский балтырганын" бетерү буенча чаралар аның чәчәккә бөреләнгәнгә һәм чәчәк ата башлаганга кадәр уткәрелергә тиеш.

"Сосновский балтырганын" бетерү буенча чаралар түбәндәге ысуллар белән уткәрелергә мөмкин:

Химик матдәләр кулланып - балтырган үскән җиргә гербицидлар һәм арборицидлар сибү;

механик - чаптыру, коры үсемлекләрне җыю, тамыр системасын казып алу;

агротехник -туфракны эшкәртү, купьеллык үләннәр чәчү.

Җир кишәрлекләрендә "Сосновский балтырганын" бетерү буенча чаралар уткәрмәгәндә ,кисәтү яки административ штраф салу күздә тотыла».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес http://pravo.tatarstan.ru/ буенча, шулай ук Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:/ mendeleevsk.tatarstan.ru. адресы буенча халыкка игълан итәргә

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлеге Советы рәисе И.И.Әһлиева